**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Учаллинского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального**
**района**

ул. Советская, д. 51 , село Учалле,
Азнакаевского муниципального района,
423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«01» ноябрь 2021 ел. №3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә;

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар Җыенын уздыру вакыты-2021 елның 11 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- Халык җыенын үткәрү урыны- Якты Күл авылы, Якты Күл урамы, 15 нче йорт, Якты Күл авылындагы Күпфункцияле Үзәк;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2021 елның 01 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 йорт; Якты Күл авылы, Якты- күл урамы,15 йорт.

- сайлау хокукына ия булган Якты Күл торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Якты Күл торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 200 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бәйрәм чараларын үткәрү, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Учук», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел»га бүләк һәм сувенир продукция сатып алу буенча хезмәт күрсәтү, аппаратура алу);

- Якты Күл авылында урамнарны яктырту (лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (чит оешмалар тарафыннан юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләр күрсәтү)

ӘЙЕ КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт; Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Якты Күл авылы, Якты Күл урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә;

-Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

-Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина